КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 6 сентябрь г.Казань № 761

2019 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күләме турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2019 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнарны;

2019 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ хезмәтләре күләмен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга норматив чыгымнар һәм хезмәтләр күләмнәре турында» 2017 ел, 2 сентябрь, 627 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 6 сентябрь, 627 нче
карары белән расланды

2019 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга
амбулатор гемодиализ хезмәтләре күрсәтүне оештыруга
норматив чыгымнар

| Т/с | Гемодиализ үзәге исеме | Норматив чыгымнар |
|---|---|---|
| 1. | Җаваплылыгы чикләнгән «Диализ клиникасы» җәмгыятенең Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 2 нче йорт, Ж литеры адресы буенча урнашкан Гемодиализ үзәге | 1 процедурага 70,0 еврога эквивалент булган сумма һәм 1120,5 сум |

___________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 6 сентябрь, 761 нче
карары белән расланды

2019 елга хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручыларга амбулатор гемодиализ хезмәтләре күләме

| Т/с | Гемодиализ үзәге исеме | Үлчәү берәмлеге | Диализ хезмәтләре күрсәтү саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Җаваплылыгы чикләнгән «Диализ клиникасы» җәмгыятенең Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Хөсәен Мәүлетов урамы, 2 нче йорт, Ж литеры адресы буенча урнашкан Гемодиализ үзәге | процедура | 18 200 |

______________________________